| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МӨЭМИН-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

**2022 елның 1 июне** **№ 10**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 29 номерлы карары белән расланган Мөэмин-Каратай авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 29 номерлы карары белән расланган Мөэмин-Каратай авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктның 3 пунктчасында «,акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы,Механизаторлар ур., 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә.А.Ханнанова